**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2700**
**05.06.2020**

Башкарма комитетның 2014 елның 17 октябрендәге 6384 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә бакчачылык-яшелчәчелек участокларында, йорт яны хуҗалыкларында үстерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сезонлы киңәйтелгән сату урыннары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр халкын авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү, бакчачылык һәм яшелчәчелекне үстерүгә булышлык итү, бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнүче һәм шәхси йорт яны хуҗалыкларына ия гражданнарга ярдәм күрсәтү максатында, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 11 бүлекнең 4, 11 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 17 октябрендәге 6384 номерлы карары белән расланган (Башкарма комитетның 2018 елның 25 маендагы 2947 номерлы, 2018 елның 1 ноябрендәге 6503 номерлы карарлары редакциясендә) Яр Чаллы шәһәре территориясендә бакчачылык-яшелчәчелек участокларында, йорт яны хуҗалыкларында үстерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сезонлы киңәйтелгән сату урыннары исемлегенә, 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян иткәнчә үзгәрешләр кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| 19. | «Фонтан» базары (Ш. Усманов урамы, 41/19а) фасады буендагы участок, 41/16 торак йорты ягындагы тротуарда | Үзәк районы хакимияте |

2. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә әлеге карарны «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов